| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«13» сентября 2023г. № 138

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның
6 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 492-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 257 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (26.08.2022 № 164, 14.11.2022, № 249 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карарның 1.4 номерлы кушымтасы белән расланган, Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген сәүдәләр үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба текст буенча - регламент):

А) күрсәтелгән Регламентның 1 нче кушымтасының 16 пунктында «әлеге күчемсез мөлкәт объектлары бирелгән» сүзләрен «дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге биналар, корылмалар» сүзләренә алмаштырырга,».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Җитәкче урынбасары – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин